**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БОЛЬШЕСАЛТАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422645С.Большой Салтан,
ул. Р.Шарафеева, дом 59

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ СОЛТАН АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422645, Олы Солтан авылы,
Р.Шәрәфи урамы, 59 нчы йорт

Тел.: (84361) 27542, факс: (84361) 27542, e-mail: Bslt.Rs@tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.02.2022г. Олы Солтан авылы №3

Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең аерым административ регламентларын юкка чыгару турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Олы Солтан авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 29 апрелендә кабул ителгән «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге территориясендә Төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү буенча муниципаль контрольне тормышка ашыру буенча Административ регламентны раслау турындагы” 4 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Олы Солтан авылы, Р.Шәрәфиев урамы, 12 йорт, адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.
4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Солтан авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Сөнгатуллин